**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгынын 17.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Иске Кәшер авыл җирлеге Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары нигезендә 2024 елның 30 мартында 15.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.«Иске Кәшер авыл җирлеге Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Урта Кәшер торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Урта Кәшер торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау);
2. Урта Кәшер торак пунктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Һади Такташ урамында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм җәю, грейдирование)
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Урта Кәшер торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка өчен ягулык-майлау материаллары, ЗИЛ-131 автомашинасы Беларусь МТЗ 82.1 тракторы;
Беларусь МТЗ 82.1 тракторы ,ЗИЛ-131 автомашинасы өчен запас частьләр);
4. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Ремонт, коймалар төзү, төзелеш материаллары һәм инвентарь( триммер һәм бензопила) сатып алу, эш өчен түләү );

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 108 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 56 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 56 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл жирлегенең Урта Кәшер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Урта Кәшер торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау);
2. Урта Кәшер торак пунктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Һади Такташ урамында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм җәю, грейдирование)
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Урта Кәшер торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка өчен ягулык-майлау материаллары, ЗИЛ-131 автомашинасы Беларусь МТЗ 82.1 тракторы; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы ,ЗИЛ-131 автомашинасы өчен запас частьләр);
4. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Ремонт, коймалар төзү, төзелеш материаллары һәм инвентарь( триммер һәм бензопила) сатып алу, эш өчен түләү );

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Кәшер авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Р.Н.Дәүләтҗанов